КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 20 февраль г.Казань № 113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр составыннан җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр составыннан җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче; 2014 ел, 6 август, 572 нче; 2015 ел, 2 апрель, 211 нче; 2015 ел, 27 июль, 546 нчы; 2016 ел, 2 ноябрь, 805 нче; 2017 ел, 22 апрель, 237 нче; 2018 ел, 29 гыйнвар, 49 нчы; 2018 ел, 12 июль, 564 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 867 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1014 нче; 2021 ел, 6 август, 684 нче; 2022 ел, 22 июнь, 596 нчы; 2023 ел, 28 август, 1032 нче; 2024 ел, 19 март, 159 нчы; 2025 ел, 18 гыйнвар, 22 нче; 2025 ел, 16 август, 611 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы түбәндәгеләрне башкара дип билгеләргә:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яки мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү турында үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә:

үтенечнамәне карап тикшерә;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яки мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү күздә тотыла торган Татарстан Республикасы законының әзерләнгән проектын (алга таба – Татарстан Республикасы законы проекты) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына, «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – вәкаләтле органнар) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә килештерүгә җибәрә. Вәкаләтле органнар тарафыннан Татарстан Республикасы законы проектын карап тикшерү срогы биш көн тәшкил итә;

вәкаләтле органнар белән килештерелгән Татарстан Республикасы законы проектын электрон формада, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган документларны, үтенечнамәне һәм аңа теркәлә торган документларны (алга таба – теркәлә торган документлар) теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яки мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү (алга таба – җирләрне күчерү) күздә тотыла торган Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән алып ике көн эчендә җирләрне күчерү турында боерык чыгара;

федераль законнарда билгеләнгән җирләрне күчерүдән баш тарту өчен нигезләр булганда җирләрне күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы законы проектын килештереп, җирләрнең яки җир кишәрлекләренең сорала торган максатчан билгеләнеше расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территорияне планлаштыру документациясенә туры килүен раслый.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Татарстан Республикасы законы проекты әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән органнар белән бергә җир кишәрлеге урнашкан җирле үзидарә органына килештерүгә җибәрелә.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «карар», «беренче абзацында» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «Татарстан Республикасы законы», «дүртенче абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «карар» сүзен «Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы законы проектын һәм теркәлә торган

документларны карап тикшерә һәм аларны Татарстан Республикасы Рәисенә җибәрә.»;

әлеге карар белән расланган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин